**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе**
**“В.Ф.Тарасов исемендәге Иске Мукшы урта гомуми белем бирү мәктәбе”**

| «Раслыйм» | «Килешенде» | «Килешенде» |
|---|---|---|
| Директор: ________ Шәрәфетдинов Р.Г.<br><br>Боерык №<br>«28 » август 2014 нче ел. | Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары :<br>____________Козлова Н.В.<br><br>«28» август 2014 нче ел. | Методик берләшмә җитәкчесе:<br>______Шәрәфетдинова Г.Ф<br><br>Беркетмә № __1_<br>«25» август 2014 нче ел. |

**10 нчы “А” сыйныфы өчен татар әдәбиятыннан эш программасы**
**(рус төркеме)**
Төзүче: югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Шәрәфетдинова Гүзәл Фәсхетдин кызы

Педогогик киңәшмә
утырышында каралды.
Боерык № 1

2014-2015 нче уку елы

**Татар әдәбиятыннан эш программасы**
**10 нчы сыйныф**
**(70 сәгать)**

**Аңлатма язуы**
***Эш программасы статусы.***

Әлеге эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелгән:

1 . "Мәгариф турында" Россия Федерациясенең Законы
2. "Мәгариф турында" Татарстан Республикасы Законы
3. "2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы" (№794 от 25.10.2013)

4. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар әдәбиятын укыту программасы (татар балалары өчен), 1- 11 нче сыйныфлар. – Казан: Мәгариф, 2010).

5. 2014/2015 нче уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре.(Методик тәкъдимнәр)

6.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының МБГБУ"В.Ф.Тарасов исемендәге Иске Мукшы урта гомуми белем бирү мәктәбе" нең уку планына(Уку планы буенча боерык №179 1нче сентябрь 2014 нче ел)
7 Дәреслек: Х.Й. Миңнегулов, .Н.С. Гыймадиева. Татар әдәбияты. 10 сыйныф, 2012.

***Эш программасы структурасы***.

Татар әдәбиятыннан эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

***Эш программасының эчтәлеге.***

Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, **«укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш"**. Бу – яңа стандартта **эшлекле белем** дип атала**. Эшлекле белем** – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата:

Структурасы – теория ярдәме белән, әдәби әсәрләргә анализ ясап, эчтәлек табу. Белем компонентлары өчәү: **теория**, өйрәнелә торган **объект** һәм алар арасындагы **бәйләнеш – анализ** гамәле.

Татар әдәбиятын укытуның **максатлары:**

- матур әдәбият текстларын форма һәм эчтәлек берлегендә аңлап кабул итү, төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне белү; әдәби-тарихи процесс турында гомуми караш булдыру;

- тиз үзгәрүчән заман шартларында файдалы җитештерүчән хезмәткә яраклы, үз-үзен танып белергә һәм һәрдаим камилләштерергә әзер, рухи дөньясы бай булган шәхес **тәрбияләү**; гуманлылык карашлары,милли үзаң, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, әдәбиятка һәм халыкның мәдәни кыйммәтләренә ярату һәм хөрмәт **булдыру**;
- укучыларда әдәбиятның үзенчәлекләре турында карашларны, әдәби текстны кабул итү, образлы һәм аналитик фикерләү культурасын, автор позициясен аңлау, әдәби процессның тарихи һәм эстетик нигезләренә төшенү , эстетик һәм иҗади сәләтне, кызыксынуны **үстерү**;
- телдән һәм язма сөйләмне **үстерү**;

әдәби-теоретик белемнәр нигезендә әдәби әсәрне тарихи-әдәби җирлеген аңлап һәм сәнгати кыйммәте бөтен тулылыгында гына

ачыкланучы буларак анализлау һәм шәрехләү; төрле типтагы сочинениеләр язу; кирәкле мәгълүматларны (Интернет челтәре аша

да) табу, системалаштыру һәм файдалану **күнекмәләре** булдыру;

- туган әдәбиятта һәм башка халыклар әдәбиятында чагылыш тапкан әхлакый идеалны үзара бәйләнештә аңлау һәм әдәби-сәнгати фикерләүдәге уртак һәм милли үзенчәлекләрне ачыклау;
-

Укыту планында 10 нчы сыйныфта татар әдәбиятыннан атнага 2 сәгать вакыт бирелә. Планны “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятынукытупрограммасы”на(татар балалары өчен):1-11нче сыйныфлар.-Казан:Мәгариф, 2010.-111б. (Ә.Н.Хуҗиәхмәтов, Ф.Г.Галимуллин, З.Н.Хәбибуллина, Х.Г.Фәрдиева) нигезләнеп төзедем. Программада 68сәгать каралган,уку планы 35 атнага төзелү сәбәпле,70 сәгать үткәрелә : язучы иҗаты – 53сәгать. Класстан тыш уку –5сәгать, бәйләнешле сөйләм үстерү – 10сәгать, резерв дәресләр-2 сәгать.

| № | Төп темалар | Сәг. | Белем һәм күнекмәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Татар әдәбияты тарихына кереш. | 1 | Борынгы һәм урта гасыр әдәбияты турында белешмә. Татар әдәбияты тарихының чорлага бүленеше. Борынгы төркиләр һәм алардагы язу. |
| | | | Гомумтөрки әдәбият. Мәхмүд Кашгарый сүзлеге. “Кодатгу белек”. Йосыф Баласагунлы. Әхмәт Йүгнәки, Әхмәт Ясави, Сөләйман Бакырганый.. |
| 2 | Болгар чоры: тарихы һәм мәдәнияты | 3 | Болгар чоры: тарихы һәм мәдәнияты турында белешмә бирү |
| | Кол Гали. “Кыйссаи Йосыф” | | Тормыш юлы, иҗады турында белешмә. әсәрнең төзелеше, сюжет чыганаклары һәм схемасы. |
| 3 | Алтын Урда: тарихы һәм мәдәнияты.Казан ханлыгы: тарихы һәм мәдәнияте. | 1 | Алтын Урда чоры әдәбиятына хас сыйфатлар. Әдипләре: Рабгузый, Котб, Габделмәҗид, Харәзми, Мәхмид Болгарый, Хисам Кятиб һ.б.. |
| | Сәйф Сараи,Мөхәммәдьяр. | | Тормыш юлы, иҗады турында белешмә. “Гөлстан”, “Сөһәйл вә Гөлдерсен” поэмасыннан өзекләр уку, фикер алышу |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 | “Идегәй” дастаны | 3 | Әсәрнең төзелеше, сюжет чыганаклары, идея-эстетик үзенчәлекләре ачыклау, уку һәм фикер алышу.<br>Казан ханлыгы тарихы һәм әдәбиятына күзәтү. әдипләре: Хәсән Кайгы, Казтуган, Өмми Кәмал, Мөхәммәд Әмин, Шәрәфи, Колшәриф һ.б. турында белешмә бирү.<br>Тормыш юлы, иҗады турында белешмә”Төхвәи мәрдән”, “Нуры Содур” поэмаларын уку, фикер алышу. |
| 6 | XVII йөз әдәбияты. Мәүлә Колый. | 1 | XVII йөз әдәбиятына хас сыйфатлар. Әдипнең тормыш юлы. Иҗаты. Хикмәтләрен уку, фикер алышу. |
| 7 | XVIII йөз әдәбияты. Габдрәхим Утыз-Имәни. | 3 | XVIII йөз әдәбиятына хас сыйфатлар. Әдипнең тормыш юлы. Иҗаты. Иҗатыннан үрнәкләр уку, фикер алышу. |
| 8 | XIX йөз әдәбияты. Габделҗәббар Кандалый.<br>Шигырь төзелеше. | 3 | XIX йөз әдәбиятына хас сыйфатлар. Әдипнең тормыш юлы. Иҗаты. Иҗатыннан үрнәкләр уку, фикер алышу. Мәрсия жанры<br>Татар шигырь төзелешенә хас сыйфатлар турында белешмә. |
| 9 | Шиһабетдин Мәрҗәни. | 2 | Тормыш юлы. Күпкырлы эшчәнлеге турында белешмә. |
| 10 | Мифтахетдин Акмулла. | 2 | Әдипнең тормыш юлы. Иҗаты. Иҗатыннан үрнәкләр уку, фикер алышу. |
| 11 | Каюм Насыйри. | 3 | Әдипнең тормыш юлы. “Әбүгалисина кыйссасы”ннан өзекләр уку, фикер алышу. |
| 12 | Муса Акъегет | 3 | Әдипнең тормыш юлы. Иҗаты. “Хисаметдин менла” повестеннән өзекләр уку, фикер алышу, анализ. |
| 13 | Заһир Бигиев<br><br>XX йөз әдәбияты. | 3 | Әдипнең тормыш юлы. Иҗаты. “Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә” романыннан өзекләр уку, фикер алышу, анализ<br>XX йөз әдәбиятына хас сыйфатлар. |
| 14 | Гаяз Исхакый | 3 | Әдипнең тормыш юлы. Иҗаты. “Ул әле өйләнмәгмн иде” повестеннән өзекләр уку, фикер алышу, анализ |
| 15 | Габдулла Тукай | 3 | Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Гасыр башындагы әдәбият үсешенә керткән өлеше. “Милли моңнар”, “Сәрләүхәсез”, “Сөй гомерне” шигырьләрен уку, анализлау. |
| 16 | Дәрдемәнд. | 3 | Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Кораб” һ.б шигырьләрен уку, анализ, фикер алышу. |
| 17 | Бакый Урманче, Нәҗип Җиһанов, Габдулла Шамуков | 3 | Тормыш юлы, иҗатлары турында белешмә |
| 18 | Сәгыйт Рәмиев | 2 | Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Таң вакыты”, “Мин” һ.б шигырьләрен уку, анализ, фикер алышу. |
| 19 | Галиәсгар Камал | 3 | Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Бүләк өчен” комедиясен уку, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | анализ. |
| 20 | Фатих Әмирхан | 3 | Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Хәят” повестен уку, фикер алышу, анализ. |
| 21 | Мирхәйдзр Фәйзи | 4 | Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Галиябану” драмасын уку, фикер алышу, анализ. |
| 22 | Шәехзадә Бабич | 1 | Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Иҗатыннан үрнәкләр уку, фикер алышу |
| | Класстан тыш уку | 5 | |
| | Бәйләнешле сөйләм үстерү | 10 | |
| | Резерв | 2 | |

***Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы.***

Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:

3. сүз сәнгатенең образлы табигате;
4. өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеге;
5. классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп факторлары;
6. төп әдәби-теоретик төшенчәләр;
7. әдәби-тарихи процессның төп закончалыклары һәм әдәби юнәлешләрнең үзенчәлекләре;
8. әдәби текстның эчтәлеген сөйләп аңлату;
9. әдәбият тарихы һәм теория буенча белемнәргә (тема, проблема, идея, пафос, образлар системасы, сюжет-композиция, телнең сәнгати сурәтләү чаралары, әдәби деталь) нигезләнеп, әдәби әсәрне анализлау һәм шәрехләү; өйрәнелә торган әсәрнең аерым эпизодын (яисә күренешне) анализлау, аның тулы әсәр эчтәлеге белән бәйләнешен аңлату;
10. әдәби әсрне иҗтимагый һәм мәдәни тормыш күренешләре белән бәйлелектә аңлату; әдәби әсәрне тарихи-конкрет һәм гомумкешелек кыйммәтләрен ачу; әдәбияттагы “үтәли” һәм “мәңгелек” проблемаларны ачыклау; әсәрне чорга хас әдәби юнәлеш белән бәйлелектә тикшерү, аңлату;
11. әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
12. әдәби әсәрне чагыштырып бәяләү;
13. автор позициясен ачыклау;
14. әдәби әйтелеш таләпләрен саклаган хәлдә өйрәнелгән әсәрләрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
15. өйрәнелгән әсәргә дәлилле рәвештә үз мөнәсәбәтеңне белдерү;
16. укыган әсәргә рецензия һәм әдәби темаларга төрле жанрда сочинениеләр язу;
17. рус һәм татар телендәге уртак һәм милли үзенчәлекләрен билгеләү, әхлакый кыйммәтләрнең чагылышын чагыштырып бәяләү;
18. әдәби сурәт чараларын тиешенчә кулланып, татар әдәби текстларын рус теленә һәм киресенчә тәрҗемә итү;
19. татар һәм рус телендәге әсәрләргә телдән һәм язмача фикереңне белдерү, аларга бәя бирү;

20. диалогта яисә бәхәстә катнашу;
21. сүз сәнгатенең аерым күренешләре белән мөстәкыйль танышу һәм аларның эстетик кыйммәтен бәяләү;
22. татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
23. эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;

**10нчы сыйныфны тәмамлаган татар балалары үзләштерергә тиешле белем-күнекмәләр:**

-халык авыз иҗаты жанрларыннан бәет, дастан, риваятьләр турында мисаллар китереп, аларга аңлатма бирә белү;
-аларның текстларыннан өзекләр китереп, мәгънәсен ачыклап бирә белү;
-әдипләрнең тормыш юлы һәм иҗаты турында тулырак мәгълүмат бирә белү;
-татар әдәбияты тарихын чорларга бүлә белү;
-5-9нчы сыйныфларда үзләштергәннән ты,19-20нче гасыр әдәбияты турында өстәмә мәгълүмат туплап, аңлатып бирә белү;
-әдәби әсәрләрнең сурәтләү чараларыннан метафора, эпитет, чагыштыру, җанландыру, гипербола, аллегория һ.б. белү һәм мисаллар белән дәлилли алу;
-әдәби төрләр һәм жанрлар;
-әдәби әсәрнең эчтәлеген һәм төзелешен( тема, идея, сюжет, композиция, образлар системасы) анализлый белү;
-тестның исеме, андагы таныш сүзләр ярдәмендә укучыларның эчтәлекне аңлаулары;
-укылган текст буенча әңгәмәдә катнаа алу, сөйләмдә гади һәм җәенке җөмләләрдән файдаланауа алу;
-өйрәнелгән язучылар турында сөйләп бирү;
-укылган текстның эчтәлеген сөйли һәм нәтиҗә ясый белү, аңа үз мөнәсәбәтеңне белдерә алу;
-тәкъдим ителгән ситуация, тема яки рәсем буенча 12-14 җөмләдән торган текст белән сөйли белү;
-уку һәм сөйләм барышында орфоэпик нормаларны саклау;
-балалар өчен басылган матбугат материалларын уку һәм файдалана алу.

## Укыту – методик комплекты

1.“Рус телендә урта( тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы”на (татар балалары өчен):1-11нче сыйныфлар.-Казан: Мәгариф, 2010,-111б. (Ә.Н.Хуҗиәхмәтов, Ф.Г.Галимуллин, З.Н.Хәбибуллина, Х.Г.Фәрдиева).

2.Рус мәктәпләрендәге татар балаларына татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты.(Казан, 2008**.)**

3.10 нчы сыйныфта татар әдәбияты дәреслеге. (Х.Й. Миңнегулов, .Н.С. Гыймадиева. Казан, “Мәгариф”, 2005.)

**Дәреслек.** Х.Й. Миңнегулов, .Н.С. Гыймадиева. Татар әдәбияты. 10 сыйныф, 2012.

4. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма/Д.Ф.Заһидуллина, М.И.Ибраһимов,В.Р.Әминева.-Казан:Мәгариф,2005

5. Әдәбият дәресләрендә бәйләнешле сөйләм үстерү: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-6нчы сыйныфларында эшләүче укытучылар өчен кулланма/Я.Х.Абдрәхимова.-Казан: Мәгариф,2007

6.”Әдәбият” предметын укыту үзенчәлекләре(татар әдәбиятын укыту буенча тәкъдимнәр)Казан 2014.

| № | Бүлекләр һәм темалар | Сәг. сан ы | Дәрес тибы | Үзләштерелергә яки камилләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр | Контроль төре | Өй эше | Дәрестә кулланылган эш төрләре | Ва кы ты .П ла н | Фа -кт |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Татар әдәбияты тарихына кереш. БСҮ. Гомумтөрки чорында иҗат итүчеләр. | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Борынгы һәм урта гасыр әдәбияты турында белешмә. Татар әдәбияты тарихының чорларга бүленеше. Борынгы төркиләр һәм алардагы язу. Гомумтөрки әдәбият. Мәхмүд Кашгарый сүзлеге. “Котадгу белек”. Йосыф Баласагунлы. Әхмәд Йүгнәки, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый. | Фронталь сорау | Укырга, конспект Укырга, сөйләргә әзерләнергә. | | **05. 09** | |
| 2. | Болгар чоры: тарихы һәм мәдәнияты. | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Болгар чоры: тарихы һәм мәдәнияты турында белешмә бирү | | Укырга, сөйләргә әзерләнергә. | Ибне Фадлан язмасы. | 06. 09 | |
| 3-4 | Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. | 2 | Уку-анализ | Кол Гали турында белешмә бирү. Әсәрнең төзелеше, сюжет чыганаклары һәм схемасы, идея-эстетик үзенчәлекләре, халкыбызның рухи тормышында тоткан урыны. | Фронталь сорау | Өзек ятларга. | Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф китабы” | 12. 09 13. 09 | |
| 5 | Ктү. “Кол Гали.” | 1 | КТУ | Әсәр белән танышуны. дәвам итү. | | | | 19. 09 | |
| **6.** | **БсҮ”Кыйссаи Йосыф” әсәрендә гуманистик идеалларның бирелеше.** | **1** | **БСҮ** | | **Язма эш** | | **Сочинение язарга.** | **20. 09** | |
| 7 | Алтын Урда: тарихы һәм мәдәнияты. Котб. Габделмәҗид. | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Алтын Урда чоры әдәбиятына хас сыйфатлар. Әдипләре турында белешә. Әдипләре турында белешә. Тормышы һәм иҗаты турында белешмә | Фронталь сорау | Укырга, конспект. “Күңел”газәлен ятларга. | | 26. 09 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Газәл жанры.<br>Сәйф Сараи | | | | | | | | |
| 8 | Кл.т уку.«Гөлестан». | 1 | КТУ | Әсәрнең төзелеше, тематик яктан төрлелеге, төп фикере. | | Укырга, эчтәлеген сөйләргә. | | 27.<br>09 | |
| | «Сөһәйл вә Гөлдерсен». | | | Табигате белән лиро-эпик җанр булу, вакыйгаларны хикәяләү фәлсәфи лирик уйланулар белән аралашып бару. | | | | | |
| 9-10 | Дастан турында төшенчә.<br>«Идегәй». | 3 | Уку-анализлау | Дастан жанры өчен хас сыйфатлар.<br>Әсәрнең төзелеше, сюжет чыганаклары һәм схема -сы, идея-эстетик үзенчәлек- ләре, халкыбызның рухи тормышында тоткан урыны. | Фронталь сорау | Өзек ятларга | “Идегәй”дастан ы | 03.<br>10<br><br>04.<br>10 | |
| 11 | Кту. “Идегәй”<br>Казан ханлыгы чоры. XV-XIV йөз әдипләре.<br>Мөхәммәдьяр “Төхфәи мәрдән”, “Нуры Содур” поэмалары. | 1 | КТУ | Дастанны тулысынча өйрәнү.<br>Казан ханлыгы тарихы  һәм әдәбиятына күзәтү.  Әдипләре: Хәсән Кайгы, Казтуган, Өмми Кәмал, Мөхәммәд Әмин, Шәрәфи, Колшәриф һ.б. турында белешмә бирү.<br>Язучы турында белешмә<br>Поэмаларның төзелеше, төп проблематикасы,  сәнгатьчә эшләнеше. | тест<br>Язма эш<br>Фронталь сорау | Әдипләр турын -да реферат.<br>“Тел турында” – ятларга. | “Идегәй”дастан ы | 10.<br>10 | |
| 12 | XVII йөз әдәбияты Мәүлә Колый. Хикмәтләре. | 1 | Яңа материал белән таныштыру<br>Уку-анализлау | XVII йөз әдәбияты тарихына һәм әдәбиятына кыскача күзәтү.<br>Тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Аның хикмәтләре. Алардагы тема төрлелеге. Әсәрләрдә дөньявилык һәм суфилык. Хезмәт кешесенә мөнәсәбәт. Күңел каршылы -гының чагылышы. Хикмәт -ләрдәге сурәтләү чаралары. | | Укырга, конспектларга.<br>Укырга, сөйләргә | | 11.<br>10 | |
| 13 | XVIII йөз әдәбияты. | 1 | Яңа материал белән таныштыру | XVIII йөз тарихы һәм әдәбиятына күзәтү.  Татар әдәбиятында жанрлар һәм бу чорда иҗат иткән әдипләр турында  белешмә бир | | Укырга, сөйләргә. | | 17.<br>10 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 14-15 | Габдерәхим Утыз-Имәни. Тормыш юлы һәм иҗаты. Мәрсия жанры | 2 | Уку-анализлау | Иҗаты турында белешмә. Тематикасының төрлелеге, фикер каршылыклары, әсәрлә- рендә үгет – нәсыйхәтнең чагылышы. Реаль күренеш -ләрнең эзлекле сурәтләнүе. Мәрсия жанры турында белешмә | Фронталь сорау | "Гыйлемнең өстенлеге турын - да" – ятларга. | | 18 10<br><br>24 10 | |
| 16 | XIX йөз әдәбияты | 1 | Яңа материал белән таныштыру | XIX йөз әдәбияты тарихына һәм әдәбиятына кыскача күзәтү. | | Укырга, конспктларга. | | 25 10 | |
| 17-18 | Габделҗаббар Кандалый иҗаты | 2 | Уку-анализлау | Тормыш юлы һәм иҗаты.. «Сахибҗәмалга»поэмасы. Шагыйрьнең әдәбиятка алып килгән яңалыгы. Әсәрдә мәхәббәтнең чагылышы. | тест | Сочинениегә әзерләнеп килергә.: «Г.Кан -далый мәхәббәт җырчысы» | | 31 10<br><br>01 11 | |
| **19.** | **Бсү. Сочинение : «Г. Кандалый мәхәббәт җырчысы» Шигырь төзелеше.** | **1** | **БСҮ** | **Язма сөйләм күнекмәләрен үстерү. Татар шигыре төзелешенә хас сыйфатлар турында белешмә бирү.** | **Язма эш** | **Конспектларга.** | | **14 11** | |
| 20-21. | Шиһабетдин Мәрҗәни. Тормыш юлы һәм иҗаты. | 2 | Уку-анализлау | Тормышы һәм күпкырлы эшчәнлеге турында белешмә. | | «Мәрҗәни-татар дөньясының мөх - тәрәм заты» - сочинениегә әзерлән. | | 15 11<br><br>18 11 | |
| **22** | **Бсү "Мәрҗәни-татар дөньясының мөхтәрәм заты"** | **1** | **БСҮ** | **Сөйләм телен үстерү.** | **Язма эш** | **Язып бетерергә.** | | **22 11** | |
| 23-24. | Мифтахетдин Акмулла. Тормыш юлы һәм иҗаты. | 2 | Уку-анализлау | Тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Аның аерым әсәрләре, аларның идеясе. | | «Акмулла – мәгърифәт һәм гаделлек җыр - чысы»- сочине – ние. | | 25 11<br><br>29 11 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **25** | **БСҮ “Акмулла – мәгърифәт һәм гаделлек җырчысы”** | **1** | **БСҮ** | **Сөйләм телен үстерү.** | **Язма эш** | **Язып бетерергә.** | | **02 12** | |
| 26. | Каюм Насыйри. Тормыш юлы һәм иҗаты. | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Тормышы һәм күпкырлы эшчәнлеге турында белешмә. | | | | 06 12 | |
| 27-28 | Каюм Насыйри «Әбүгалисина кыйссасы». | 2 | Образлар аша анализ ясау | Фантастик сурәтләү алымы -ның сюжетны оештырудагы әһәмияте. гуманистик идея -ләрнең яклануы, хаксызлыкка каршы көрәш. Сатирик әсәрдә алымнар, ironияле сурәтләү | | Укырга, үз сүзләрең белән сөйләргә. | | 09 12<br><br>13 12 | |
| 29. | Кту. Каюм Насыйри «Тәрбия китабы» | 1 | КТУ | | тест | | | 16 12 | |
| 30. | Муса Акъегет. Тормыш юлы һәм иҗаты | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Тормыш юлы һәм иҗаты. | | | | 20 12 | |
| 31-32 | Муса Акъегет «Хисаметдин менла». | 2 | Образлар аша анализ ясау | Әсәрдә искелек тарафдар -ларының тәнкыйтьләнүе, аларга алмашка килгән яңа кешеләрне күрсәтергә омтылыш, хатын – кыз язмышы мәсьәләсенең бирелеше. | | «Хисаметдин менла» романы -ның татар әдәбиятындагы урыны» -темасына сөйләшүгә әзерләнеп килергә. | | 23 12<br><br>27 12 | |
| 33 | Заһир Бигиев. Тормыш юлы һәм иҗаты . | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Тормышы һәм иҗаты. | | Укырга, конспектларга. | | 13 01 | |
| 34-35 | Заһир Бигиев. «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә». | 2 | Дәрес-әңгәмә | Әсәрнең темасы, идеясе, образларының бирелеше, композицион төзелеше. | тест | укырга, образ -ларга характерис -тика, анализлар | | 17 01 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | 20 01 | |
| 36 | XX йөз башы әдәбияты. | 1 | Яжа материал белән таныштыру | XX йөз башы әдәбияты татар әдәбиятына күзәтү. | | Конспектларга, сөйләргә. | | 24. 01 | |
| 37-38 | Гаяз Исхакый Тормыш юлы һәм иҗаты . | | | Тормышы һәм иҗаты. | Фронталь сорау | Әдипнең эш - чәнлеге турында сөйләргә. | | 27. 01<br><br>31. 01 | |
| | Гаяз Исхакый «Ул әле өйләнмәгән иде». | 2 | Дәрес- әңгәмә | Әсәрдә катнаш гаилә мәсьәләсенең чагылышы. Холык, әхлакый нигез һәм кеше язмышы мәсьәлә- ләренең үзара тиз керешүе. | | укырга, образ - ларга характерис - тика, анализлар | | | |
| **39** | **БСҮ.Катнаш никахка минем мөнәсәбәтем.** | **1** | **БСҮ** | | **Язма эш** | | **Сочинениене язып бетер.** | **03. 02** | |
| 40 | Кту. Гаяз Исхакый, «Кәләпүшче кызы». | 1 | КТУ | | Г.Исхакый иҗаты буенча зачет | | | 07. 02 | |
| 41 | Габдулла Тукай. Тормыш юлы һәм иҗаты | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Шагыйрьнең гасыр башын -дагы әдәбият үсешенә керткән өлеше. Тукай образының әдәбиятта, музыкада, сынлы сәнгатьтә чагылышы | | Укырга, конспектларга. | | 10. 02 | |
| 42-43 | Габдулла Тукай «Милли моңнар». Сәрләүхәсез». | 2 | Сәнгатьле сөйләм үстерү | Шигырьләрдә шагыйрь һәм милләт язмышы мәсьәләсе. Әсәрләрнең темасы һәм идеясе. | Тукай иҗаты буенча зачет | «Милли моңнар». – ятларга. | | 14. 02<br><br>17. 02 | |
| **44** | **БСҮ.Тел- милләт сакчысы.** | **1** | **БСҮ** | **Сөйләм телен үстерү.** | **Фронталь сорау** | | **Сочинениене язып бетер.** | **21. 02** | |
| 45 | Композитор | 1 | Яңа | Яңа материал белән таныштыру | | | | 24. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Нәҗип Җиһанов. | | материал белән таныштыру | | | | | 02 | |
| 46 | Рәссам Бакый Урманче. | 2 | Яңа материал белән таныштыру | Иҗаты турында белешмә. | | Укырга,сөйләргә. | | 28. 02 | |
| 47 | Сәгыйт Рәмиев. Тукай. Тормыш юлы һәм иҗаты | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Тормыш юлы һәм иҗаты. | | Укырга,хрон.табл. төзергә. | | 03. 03 | |
| 48 | Сәгыйт Рәмиев. “Таң вакыты”,”Мин” шигырьләре. | 1 | Сәнгатьле сөйләм үстерү | Авторның шигырьләрдә үткәргән карашлары бирелеше. | | “Таң вакыты” ятларга. | | 07. 03 | |
| 49 | Дәрдемәнд. Тормыш юлы һәм иҗаты | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Тормыш юлы,иҗаты турында белешмә. | Фронталь сорау | Укырга, сөйләргә. | | 10. 03 | |
| **50-51** | Дәрдемәнд «Кораб», «Бәллү», «Видагъ», Татарлыгын татар һич гарь итәрме». | 2 | Сәнгатьле сөйләс үстерү | Әсәрләрнең темасы һәм идеясе. | | «Кораб», «Татар -лыгын татар һич гарь итәрме»- ятл | | **14. 03** **17. 03** | |
| 52 | Галиәсгар Камал. Тормыш юлы һәм иҗаты | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Иҗаты турында белешмә. | | Укырга, сөйләргә. | | 21. 03 | |
| 53-54 | Галиәсгар Камал. «Бүләк өчен». | 2 | Образлар аша анализ ясау | Әсәрнең проблематикасы, образлар бирелеше. | | «Г.Камал – тел остасы» дигән темага сочинениегә әзерлән. | | 04. 04 07. 04 | |
| **55** | **БСҮ.”Г.Камал-тел остасы”** | | **БСҮ** | **Сөйләм телен үстерү.** | **Язма эш** | **Язып бетер.** | | **11. 04** | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 56 | Артист һәм язучы Габдулла Шамуков. | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Иҗаты турында белешмә. | | Хронологик табл. төзергә. | | 14. 04 | |
| 57 | Фатих Әмирхан. Тормыш юлы һәм иҗаты | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Иҗаты турында белешмә. | | Укырга, сөйләргә. | | 18. 04 | |
| 58-59 | Фатих Әмирхан «Хәят». | 2 | Дәрес-әңгәмә | Әсәрнең идеясе, кеше психологиясен тасфирлауда авторның осталыгы. | **Фронталь сорау** | укырга, образ - ларга характерис - тика, анализ, өзек ятларга. | | 21. 04<br>25. 04 | |
| **60** | **БСү”Ф.Әмирханның “Хәят” повестенда яшь кеше кичерешләренең чагылышы”** | | **БСү** | | | **Сыйфатлама-сочинениене язарга.** | | 28. 04 | |
| 61 | Мирхәйдәр Фәйзи. Тормыш юлы һәм иҗаты | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. | | Укырга, сөйләргә. | | 02. 05 | |
| 62-63-64 | Мирхәйдәр Фәйзи «Галиябану». | 3 | Уку-анализлау | Әсәрдә мәхәббәт гүзәллеге, сафлыгы, образлар бирелеше. Драманың халык тормышын- нан алынып язылган, җыр һәм музыка кергән беренче әсәр - ләрнең берсе булуы. | | укырга, образ - ларга характерис - тика, анализлар , өзек ятларга. | | 05. 05<br>09. 05<br>12. 05 | |
| **65** | **Бсү.М.Фәйзинең “Галиябану”драмасында** | **1** | **БСҮ** | | | **Сочинение язып килергә.** | | **16. 05** | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | **конфликт бирелеше.** | | | | | | | | |
| 66 | Шаехзадә Бабич. Тормыш юлы һәм иҗаты | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Тормышы һәм иҗаты. | | | | 19. 05 | |
| 67 | Кл т уку «Кандала». Иҗатыннан үрнәкләр. | 1 | КТУ | Әсәрдәге нечкә юмор, тәнкыйть фикеренең тирәнгә яшеренүе. | Фронталь сорау | 1 шигырен ятларга. | | 23. 05 | |
| **68**<br><br>**69-** | **Бсү. Мәгърифәт учаклары.** | **1**<br><br>**2** | **БСҮ** | **Татар мәдрәсәләре турында кыскача белешмә.** | **Язма эш** | **Рефератлар.** | | **26. 05**<br><br>**30. 05** | |
| **70** | **Резерв дәресләр** | **1** | | | | | | 30. 05 | |

**Татар әдәбиятыннан сочинениене бәяләү критериясе**
**Сочинениене бәяләү**

| Мәктәп тибы<br>Билге | Рус мәктәбе | Рус телле балалар |
|---|---|---|
| “5” | Эчтәлек темага туры килә, фактик хаталары юк, теле бай, стиль бердәмлеге сакланган; 1 орфографик яисә 2 пунктуацион (грамматик) хата. | Эзлекле язылган һәм эчтәлек тулысынча ачылган; 1 орфографик, 1 пунктуацион яки 2 грамматик хата. |
| “4” | Эчтәлек нигездә темага туры килә; зур булмаган ялгышлыклар күзәтелә; 1-2 фактик хата; 2 орфографик, 3 пунктуацион ( грамматик) яисә бер-ике сөйләм хатасы. | Тема эзлекле язылган, ләкин 2-3 эчтәлек ялгышы, 2-3 орфографик, 2-3 пунктуацион хата. |
| “3” | Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлыклар, фактик төгәлсезлекләр; эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаган;теле ярлы; орфографик, 4 пунктуацион (грамматик) яисә 3-4 сөйләм хата. | Тема өлешчә эзлекле язылган; эчтәлек тулысыңча ачылмаган; 4-5 орфографик, 4-5 пунктуацион хата. |
| “2” | Язма темага туры килми; Фактик төгәлсезлекләр күп; теле ярлы; текст кыска; сүзләр дөрес кулланылмаган; стиль бердәмлеге сакланмаган; 5 орфографик, 8 пунктуацион (грамматик), яисә 4-6 сөйләм хатасы. | Тема эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 6 дан артык орфографик, 6 дан артык пунктуацион һәм грамматик хата. |

## Укыту – методик комплекты

1.“Рус телендә урта( тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы”на (татар балалары өчен):1-11нче сыйныфлар.-Казан: Мәгариф, 2010,-111б.   (Ә.Н.Хуҗиәхмәтов, Ф.Г.Галимуллин, З.Н.Хәбибуллина, Х.Г.Фәрдиева).

2.Рус мәктәпләрендәге татар балаларына татар теленнән  гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты.(Казан, 2008**.)**

3.10 нчы сыйныфта татар әдәбияты  дәреслеге. (Х.Й. Миңнегулов, .Н.С. Гыймадиева.  Казан, “Мәгариф”, 2005.)

**Дәреслек.** Х.Й. Миңнегулов, .Н.С. Гыймадиева.  Татар әдәбияты. 10 сыйныф, 2012.

4. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма/Д.Ф.Заһидуллина, М.И.Ибраһимов,В.Р.Әминева.-Казан:Мәгариф,2005

5. Әдәбият дәресләрендә бәйләнешле сөйләм үстерү: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-6нчы сыйныфларында эшләүче укытучылар өчен кулланма/Я.Х.Абдрәхимова.-Казан: Мәгариф,2007

6.”Әдәбият” предметын укыту үзенчәлекләре(татар әдәбиятын укыту буенча тәкъдимнәр)Казан 2014.

**Татар әдәбиятыннан тестлар**

# I. БОРЫНГЫ ТӨРКИ ЧОР (VII – XIII гасырлар )

1. Гомумтөрки әдәби чорның вакыт кысаларын атагыз.
   А) безнең эрага кергән III – I гасырлар;
   Ә) XII – XIII йөзләргә кадәр;
   Б) урта гасырлар;
   В) XIII йөзнең урталары – XV йөзнең урталары;
2. Рун язулары истәлекләр ничәнче гасырга карыйлар?
   А) VII – VII;
   Ә) IX;
   Б) V;
   В) XIII йөзнең урталары;
3. Аталганнарның кайсысы татар-төрки әдәбиятының төп чыганакларына керми?
   А) фольклор һәм мифология;
   Ә) рун һәм уйгур язулы истәлекләр;
   Б) Коръән һәм Шәрык классикасы;
   В) рус елъязмалары.
4. Әлеге язу системаларының кайсысы төркиләр тарафыннан иң беренче булып кулланылган?
   А) рун язуы;
   Ә) һун(туран) язуы;
   Б) латин язуы;
   В) кирилл язуы;
5. Рун язуына хас булмаган үзенчәлекне билгеләгез.
   А) 60лап тамгадан торган;
   Ә) гарәп графикасына охшаган;
   Б) уңнан сулга, өстән аска язылган;
   В) күбесенчә таш, дивар, сөяк, һәм металл әйберләргә, чүлмәккә уеп язылган
6. Иң атаклы рун язулы истәлекләр кемгә багышланган?
   А) Йосыф пәйгамбәргә;
   Ә) М. Кашкарыйга;
   Б) Күлтәгин, Билгә-каган һәм Танъюкукка;
   В) Томсен белән Радловка;
7. “Ырыг битиг” (“Юрау китабы”) нәрсәгә багышланган?

А) төшләрне юраучга;
Ә) гадел патшаны мактауга;
Б) төрки каганат тарихына;
В) матур язарга өйрәтүгә;

8. Кайсы тема рун язулы истәлекләрдә урын алмаган?
А) сугыш темасы;
Ә) борынгы төркиләрнең тормыш-көнкүреше;
Б) каган хәкимиятенеңизгелеге;
В) сөйгән ярны мактау темасы;

9. “Алтын ярук” ( Алтын балкыш”) – ул ...
А) кытай теленнән тәрҗемә ителгән будда дини китабы;
Ә) Й. Баласагунлының икенче әсәре;
Б) гарәп графикасында язылган истәлек;
В) төрки телләр сүзлеге;

10. М. Кашгарыйның “Диване лөгатет-төрк” хезмәтенинди графикада язылган?
А) рун;
Ә) гарәп;
Б) уйгур;
В) латин һәм кирилл;

11.М. Кашгарыйның хезмәте беренче мәртәбә кайда һәм кайчан басылган?
А) 1839 елда Казанда;
Ә) 1915-1917 елларда Истанбулда;
Б) 1963 елда Үзбәкстанда;
В) беркайчан да басылмый;

12. “Диване лөгатет-төрк” хезмәте нинди телдә язылган?
А) тулысынча гарәпчә;
Ә) борынгы төрки телдә генә;
Б) төрки сүз һәм сүзтезмәләре, иәкальләре,шигъри юллары башта төркичә, аннан гарәпчәгә тәрҗемә итеп;
В) уйгур телендә;

13. Кайсы жанр Кашгарый сүзлегундә урын алмаган?
А) дастан һәм җырлар;
Ә) мәхәббәт шигыйрьләре;
Б) фәлсәфи лирика;
В) романнар өзекләр;

14. “Котадгу белек” әсәренең жанрын атагыз.

А) “Бәхет китабы”, “Игелекле итүчекитап”;
Ә) “Белем бәхет китерми”;
Б) “Белемсезлекнең бәхете”,” Дөньяда белемсез генә бәхетле”;
В) “Җан һәм бәхет –белемдә”, ә белемсезлектә түгел”;

15. . “Котадгу белек” әсәренең жанрын атагыз.
А) сүзлек;
Ә) лиро-эпик поэма;
Б) Богра ханга мәдхия;
В) каберташ язмасы;

16. Й.Баласагунлының “Котадгу белек” әсәрендәге төп персонажларны күрсәтегез.
А) Көнтугды, Айтулды, Үгделмеш, Узгырмыш;
Ә) Йосыф, Зөләйха, Ягъкуб һ.б.;
Б) лирик герой һәм аның сөйгән яры;
В) сюжет схематик булганга, персонажларның исемнәре юк;

17. “Котадгу белек” әсәренең үзәгендә торган иң әхәмиятле мәсьәлә-
А) кешеләрдәге тискәре сыйфатларны тәнкыйтьләү;
Ә) идарәчелек проблемасы;
Б) яшәү белән үлемнең каршылыгы;
В) мәхәббәт фаҗигасы;

18. Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганыйның иҗатларын иң элек нәрсә берләштерә?
А) бер үк чорда һәм бер үк шәһәрдә яшәгәннәр;
Ә) икесе дә бер үк укытучыда белем алганнар;
Б) аларның шигырьләре идея-тематик һәм поэтик яктан охшаш-икесе дә дини-суфычыл характерда;
В) икесе дә Коръәнне яттан белгәннәр;

19. Әхмәд Ясәви һәм С. Бакырганый шигъриятендә төп тема-
А) гадел патша һәм гадел җәмгыять;
Ә) илаһи мәхәббәт, Аллаһның чиксез ярату;
Б) идеаль кеше тәрбияләү;
В) ихласлы гыйбәдәткә омтылу;

20. Шәрык классик әдәбиятенең төрки-татар әдәбиятына тәэсире нәрсәдә <u>күренми?</u>
А) китапларның тышкы бизәлешендә һәм нәшер ителүендә;
Ә) төп тема, сюжет, образларның уртак булуында( нәзирәчелек);
Б) гарәп-фарсы алынмалары һәм төшенчәләре керүдә;
В) шигъри жанрларны үзләштерүдә;

21. Коръән турында <u>булмаган</u> фикерне күрсәтегез.

А) 23 ел буена әз-әзләп Мөhәммәд пәйгамбәргә иңә;
Ә) Аллаhның берлеген, пәйгамбәрлекне раслый;
Б) 100 сүрәдән тора;
В) ахирәт көне турында искәртә;

22. Коръән ничәнче елларда кешеләргә иңә?
А) VII гасырның икенче яртысында;
Ә) безнең эрага кадәр үк;
Б) 1250-1273 елларда;
В) 610-632 елларда;

**Татар әдәбиятыннан тестлар.**

## II. БОЛГАР ЧОРЫ ӘДӘБИЯТЫ( XII-XIII гасыр уртасы)

1.Кол Гали кайсы Болгар дәүләтендә яшәгән?
А) Бөек Болгар дәүләте;
Ә) Болгария;
Б) Идел буе Болгар дәүләте;
В) Хәзәр дәүләте;

2. Хәзәрләр белән болгарлар үзара тугандаш халыкլармы?
А) әйе;
Ә) бик үк түгел;
Б) юк;
В) белмим;

3. Кол Галинең туган елын күрсәтегез.
А) 1183;
Ә) XIII гасырның икенче яртысы;
Б) 1671;
В) 1212;

4. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәрен беренче булып басмага кем әзерләгән?
А) ГюУтыз-Имәни;
Ә)Мөhәммәдьяр;
Б) Х.Миңнегулов;

В) Н.Хисамов;

5. Болгар дәүләтендә ислам дине рәсми рәвештә кайчан кабул ителә?

А) 512 елда;

Ә) 1023 елда;

Б) 922 елда;

В) 1902 елда;

6. Кол Галинең әсәрен ничек дип <u>атамыйлар?</u>

А) “Йосыф кыйссасы”;

Ә) “ Йосыф-Зөләйха”;

Б) “Зөләйха китабы”;

В) “Йосыф китабы”

7. Кол Галинең туган җире дип фаразланган шәһәрне күрсәтегез.

А) Бохара;

Ә) Сарай-Бату;

Б) Болгар;

В) Кашан(Кышан);

8. “Кыйссаи Йосыф”ның строфалары ничек рифмалаша?

А) aааб, вввб, гггб;

Ә) аа, бб, вв, гг…;

Б) абвб, гбдб;

В) абаб,вбвб,гбгб;

9. “Кыйссаи Йосыф” әсәрендә кайсы өлеш <u>юк?</u>

А) кереш;

Ә) төп өлеш;

Б) эпилог;

В) хатимә;

10. “Кыйссаи Йосыф” әсәре нәрсә белән башланып китә?

А) Йосыф пейгамбәрнең төше белән;

Ә) Аллаһка, Мөхәммәд пәйгамҗәргә, хәлифләргә һ.б.ларга мәдех-мактау белән;

Б) эпиграф белән;

В) Йосыф пзйгамбәрнең кыяфәтен сүрәтләү белән;

11. 11 яшьлек Йосыф пәйгамбәр төшендә нәрсә күрә?

А) тулган ай белән 11 йолдызның аңа баш июен;

Ә) үзенең бөтен киләсе тормыш вакыйгаларын;

Б) агаларының үзенә хезмәт итәчәкләрен;

В) 12 йолдыз белән кояшның аңа сәҗдә итүен;

12. “Хәр начарлык җәзасын ала” принцибы поэманың кайсы вакыйгасына туры килми?

А) Кылычның Йосыф пәйгамбәрне юк гаеп белән кыйнавы;

Ә) агаларының Йосыф пәйгамбәрне кыйнап, кол итеп сатып җибәрүе;

Б) Ягъкуп пәйгамбәрнең кол баланы анасыннан аеруы;

В) Йосыф пәйгамбәрнең яңа шәһәргә нигез салуы;

13. Йосыф пәйгамбәрне сатып алырга байлыгы җитмәгәч, Кыйтфир Дәгыйрга нәрсә тәкъдим итә?

А) үзенең патша сараен;

Ә) калган бәясын соңрак бирергә;

Б) җитмәгәнен бүләк итеп бирергә;

В) үзенең хатын бирергә.

14. Йосыф пәйгамбәр ни өчен зинданга утыртыла?

А) Зөләйхага бәйләнгәне өчен;

Ә) патша урынын алырга теләгәне өчен;

Б) илне корылыктан коткарыр өчен;

В) үзе теләп-гөнаһтан качар өчен;

15. Ягъкуб пәйгамбәрнең уллары нигә Мисырга киләләр?

А) ашлык сорап;

Ә) Йосыф пәйгамбәрдән гафу үтенергә;

Б) күңел ачарга;

В) хатын эзләргә;

16. Йосыф пәйгамбәр нигез салган яңа шәһәрнең исеме ничек?

А) Йосыф;

Ә) Әмин;

Б) Казан;

В) Антананариву;

17. Кол Гали үзенең әсәрен язганда гомумән кулланмаган чыганакны күрсәтегез.

А) Коръәндәге”Йосыф” сүрәсе;

Ә) Фирдәүсинең поэмасы;

Б) Н. Хисамовның әсәре;

В) үзенең иҗади фантазиясы;

18. Кол Галиның поэмасы халыкта бик популяр була. Бу күренеш нәрсәгә <u>бәйле булмый?</u>

А) әсәр күләменең зур булуына;

Ә) халыкка рухи тарафтан якын булуына;

Б) әдәби әсәр буларак камил эшләнгәнлегенә;

В) бу сюжетның Коръәннән үк килүенә;
19. Йосыф пәйгамбәр белән Зөләйха ни өчен бер-берсенә каршы куеп тасвирланалар?
А) Ислам диненең мәҗүсилектән өстән икәнен күрсәтер өчен;
Ә) төп геройның рухи яктанөстәнлеген исбатлар өчен;
Б) әсәрнең конфликтын көчәйтү максатыннан;
В) әсәрнең мәхәббәт сызыгын тагын да кызыклырак итер өчен;
20. Йосыф пәйгамбәрнең “ун төрле һөнәре” арасында кайсылары урын алмаган?
А) зифа буй, нурлы йөз, саф тел;
Ә) пәйгамбәр нәселе, гүзәл холк, ышанычлык;
Б) укымышлылык, оста сөйләү, яхшы киенү;
В) тугры сүз, диненең бөтенлеге, батырлык;
21. Ни өчен Йосыф пәйгамбәр кол булып сатыла?
А) үзе теләгәнгә;
Ә) көзгегә карап масайганы өчен;
Б) агаларына каршы чыкканы өчен;
В) артык сабырлы булганга;
22. Кол Гали поэмасы нигә Яңарыш(Ренессанс) дәверенең үрнәге дип санала?
А) XIII гасырның башында язылганга;
Ә) пәйгамбәр тормышын сүрәтләгәнгә;
Б) кешене олылавы, хөрмәт итүе аркасында;
В) Ислам динен алга сугарганы өчен;
23. “Кыйссаи Йосыф” әсәрендә урын алмаган сәнгатьчә сүрәтләү алымын күрсәтегез.
А) төш күрү һәм аны юрау;
Ә) сарай төзү вакыйгасы;
Б) боҗралы композиция;
В) әкияти арттыру, могҗизалы хәлләр, символик саннар куллану.

**Татар әдәбиятыннан тестлар.**

# III. АЛТЫН УРДА ЧОРЫ ӘДӘБИЯТЫ(XIII г. Уртасы-XVг.уртасы)

1.Алтын Урдада дәүләт теле дип кайсы тел атала?
А) уйгур һәм төрек телләре;
Ә) кыпчак(татар) теле;
Б) монгәл теле;
В) рус теле;
2. Кайсы язма истәлекләр Алтын Урда чорына кертелмиләр?

А) ярлыклар һәм фәнни хезмәтләр;
Ә) сәяхәтнәмә һәм сүзлекләр;
Б) каберташ язмалары;
В) рун язма истәлекләре;

3. Ярлык- нәрсә ул?
А) хөкемдарның язма указы, фәрманы, грамотасы;
Ә) борынгы заманнарда кешеләргә тагылган тамга;
Б) кешеләрне бер-берсеннән аера торган үзенчәлек;
В) каберташ язмаларының бер төре;

4. Алтын Урда чорының шигъри ядкәрен күрсәтегез.
А) Котб ”Хөсрәү вә Ширин”;
Ә) Мәүлә Колый”Береккәннәр сыйфаты”;
Б) Мөһәммәдьяр”Нуры содур”
В) Г.Тукай” Исемдә калганнар”;

5. “Кодекс Куманикус” язма истәлекләрнең кайсы төркеменә керә?
А) монголларның каберташ язмасы;
Ә) Куман иленә сәяхәтнамә;
Б) Болгариның фәнни хезмәте;
В) латинча-фарсыча-кыпчакча сүзлек;

6. Алтын Урда чоры әдипләре кешеләрнең кайсы ягына иң зур әһәмият бирәләр?
А) әхлакый йөзенә һәм холкына;
Ә) дини ышануларына;
Б) хөкемдарга булган мөнәсәбетенә;
В) башкаларны сөя белүенә;

7. Әлеге чорнын кайсы әдтпләрендә суфичылык идеялары гомумән очрамый?
А) С.Сарай, Котб;
Ә) М.Болггари, Харәзмә;
Б) Рабгузый, Х.Кятиб, М.Үргәнчи;
В) юк, барысында да очрый;

8. Түбәндәге фикерләрнең кайсысы суфичыларга хас түгел?
А) Аллаһы Тәгалә каршында бар да тигез;
Ә) дөньга кимсетеп карау, аны кире кагу;
Б) башка дин кешеләрен гомумән кабул итмәү;
В) үз-үзеңне камилләштерү аркылы Аллаһка якынаеп була;

9. Мәүлә Колый фикеренчә, чын суфи-ул...

А) көне буе Аллаһка гыйбадәт белән мәшгуль булган адәм;
Ә) сүзе һәм гамәле бердәм булган идеал кеше;
Б) суфилыкны хөнәргә әйләндереп, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы;
В) үзен һәм, гомумән, бөтен дөньяны юкка санаучы;

10. Пәйгамбәрләр тарихы турында булган әсәрне һәм аның авторын атагыз.
А) Сарай"Гөлстан-бит Төрки";
Ә) Рабгузый" Кыйссасел-әнбия";
Б) Котб" Кыйссасел-әнбия";
В) "Кисекбаш" ( авторы билгесез);

11. Котб үзенең "Хөсрәү вә Ширин" әсәрен язганда кайсы шагыйрьнең әсәрен нигез итеп ала?
А) Низами;
Ә) Тукай;
Б) авторы билгесез булган поэманы;
В) Гомәр Хәйям.

12.Күләме, идея киңлеге һәм сюжет композициясенә карап, "Хөсрәү вә Ширин" әсәрен нинди жанрга кертеп була?
А) шигырь;
Ә) шигъри роман;
Б) бәет;
В) роман;

13.Харезми фикеренчә, кешедә иң олы һәм изге хис-кичереш кайсысы?
А) сөю, мәхәббәт;
Ә) башкаларны хөрмәт итү;
Б) нәфрәт;
В) эчке һәм тышкы матурлык;

14. ...Ашар йилдин синең йиләгәндә(чапканда) атың,
Кояш яңлигъ(кебек) җиһанны тотты атың...
Харезминең әлеге бәетендә нинди шигъриалым <u>кулланылмаган?</u>
А) арттыру(гипербола);
Ә) чагыштыру;
Б) омонимия(тәҗнис);
В) анафора;

15. Хисам Кятибнең әсәре кемгә багышланган?
А) Җөмҗөмә дигән көтүчегә;
Ә) Кисекбашка;
Б) Җөҗөмә исемле солтанга;

В) авторның үз тормышына;

16. Хисам Кятиб үзенең поэмасында нинди нәтиҗә чыгара?
    А) дөньяда беркем дә мәңгеллек түгел, шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк игелек кылырга кирәк;
    Ә) патша яки солтан булу-бик гөнаhлы эш;
    Б) фәкыйрьләргә ярдәм итмәгән кеше 4 мең ел буена җәhәннәмдә газап чигәчәк;
    В) мәhәббәт – дөньдагы иң матур hәм игътибарга лаек хис;
17. “Кисекбаш әсәренең Хисам Кятиб поэмасыннан төп аермасы нәрсәдә?
    А) Хисам Кятибнең поэмасы ике юллыклар белән язылган;
    Ә) “Кисекбаш”та дөньявилык көчлерәк;
    Б) киселгән баш берендә генә сөйләшә ала;
    В) “Кисекбаш”ның күләме зуррак;
18. “Нәhҗел-фәрадис” әсәренең исеме нәрсәне аңлата?
    А) юлларның иң дөресе;
    Ә) оҗмахларның ачык юлы;
    Б) оҗмахка керүнең серләре;
    В) Фирдәвесның хатирәләре;
19. М.Болгариның “Нәhҗел-фәрадис” әсәренә хас булмаган үзенчәлекне күрсәтегез;
    А) зур күләмле дини-дидактик поэма;
    Ә) барысы бергә 40 фасылдан тора;
    Б) әр бүлектә хәдис китерелә hәм берәр хикәя белән аңлатыла;
    В) сонгы ике баб үзәгендә Мөhәммәд пәйгамбәр, аның якыннары, туганнары h.б. тора.
20. “Нәhҗел-фәрадис” әсәрендә урын алган шәhх ибне Гыймран hәм кызый турындагы хикаяттә нинди фикер үткәрелә?
    А) казыйлар-кешеләр арасында иң өстеннәре;
    Ә) мохтаҗ кешегә ярдәм итмәгән әркем җәзасын алачак;
    Б) кыямәт көненең дәhшәтлеге;
    В) гадел хөкемдар бөтен җәмгыятьне дә бәхетле итәчәк;
21. С. Сарайның яшәү елларын hәм туган шәhәрен күрсәтегез.
    А) 1321-1396, Камышлы шәhәре;
    Ә) 1297-1360, Болгар шәhәре;
    Б) XII г. Уртасы- XVг. Уртасы;
    В) XII гасыр, Сарай шәhәре;
22. Түбәндәге әсәрләрнең кайсысы С.Сарай тарафыннан язылмаган?
    А) “Гөлстан-бит төрки”
    Ә) “Сөhәйл вә Гөлдерсен”

Б) “Хөсрәү вә Ширин”
В) “Күзләрең” газеле;

**Татар әдәбиятыннан тестлар.**

## IV. КАЗАН ХАНЛЫГЫ ЧОРЫ ӘДӘБИЯТЫ(XVг. Уртасы-1550 еллар)

1. Казан ханлыгы нинди дәүләтнең варисы булып санала?
   А) Русь;
   Ә) Алтын Урда;
   Б) Чынгызхан империясы;
   В) Төрки канагат;
2. Казан ханлыгында ни сәбәпле мәктәп-мәдрәсәләр, белемле кешеләр күп була?
   А) халыкның күпчелеге ислам динен тота;
   Ә) Алтын Урдадан калган традция буенча;
   Б) төзүчеләр һәм сәүдә яхшы булганга;
   В) сугышлар бик еш булып торганга;
3. Әлеге чорга караган иң күренекле фольклор истәлеген күрсәтегез.
   А) Батырша турында риваятьләр;
   Ә) “Идегәй” дастаны;
   Б) С.Сарай иҗаты;
   В) татар халык мәкальләре;
4. “Идегәй” дастанында Алтын Урда җимерелүенең төп сәбәпләре арасында кайсысы аталмый?
   А) Башка халыклар белән еш сугышулар;
   Ә) эчке бердәмлек җитми;
   Б) дәүләт эчендәге үзара ызгыш-талаш;
   В) Туктамыш ханның Идегәй атасын үтерүе;
5. Тышкы формасы ягыннан караганда, “Идегәй” дастаны әлеге чорның башка язма истәлекләреннән кайсы ягы белән аерыла?
   А) җиделе үлчәмгә корылган булуы белән;
   Ә) әкияти образлары һәм символлары белән;
   Б) строфаларның төзелеше һәм саны белән;
   В) бер ягы белән дә аерылмый;
6. “Кыйссаи Сәйфелмөлек” әсәре нәрсә белән тәмамлана?
   А) сөйгән ярларның трагик рәвештә һәлак булулары белән;
   Ә) яшьләрнең үз максатына ирешүе белән;
   Б) Алтын Урданың җимерелүе белән;
   В) Аллаһны һәм аның пәйгамберләрен мактау белән;

7. Әлеге әсәрләрнең кайсысы иң беренче нәшер ителә?
А) “Идегәй”(XVг. Уртасы)
Ә) “Исемдә калганнар”(1907);
Б) “Кыйссаи Йосыф”(1899)
В) “Кыйссаи Сәйфелмөлек”(1807);
8. “Бабахан дастаны”ның авторын күрсәтегез.
А) Сарай;
Ә) Сайяди;
Б) Сәгьди;
В) Кол Гали;
9. “Бабахан дастаны” кайсы традицион сюжетны чагылдыра?
А) Таһир-Зөһрә мәхәббәте;
Ә) Ләйлә-Мәҗнүн мәхәббәте;
Б) гадел хөкемдар проблемасы;
В) үгет-нәсыйхәт бирү;
10. Түбәндәге әдипләрнең кайсылары Казан ханлыгычорында иҗат итмәгәннәр?
А) Казтуган, Хәсән Кайгы, Мөхәммәдьяр;
Ә) Өмми Камал, Шәрифи;
Б) Колшәриф, Мөхәммәд
В) Шәмсетдин Зәки, Котб;
11. Шәрифнең “Зөфәрнамәи вилаяти Казан” әсәре нинди жанрга кертеп карала?
А) лиро0эпик поэма;
Ә) одәби-тарихи-публицистик ядъкәр;
Б) шигъри роман;
В) газәл;
12. “Зөфәрнамәи вилаяти Казан” әсәрендә нинди вакыйгалар сүрәтләнә?
А) 1550 елда Казанга ясалган Һөҗүмнең нәтиҗәсез тәмамлануы;
Ә) 1552 елда Казанны яулап алуы;
Б) Зөфәрнең Казанда күргәннәре;
В) Казан шәһәренә нигез салуы;
13. И күңел, бил баглама, күпне кичергән дөньядыр,
Бу үлем ширбәтен халыкка эчергән дәньядыр..
Колшәрифнең әлеге юлларында нинди фикер уздырыла?
А) эчүчелек проблемасы;
Ә) күңелнең алданучан булуы;

Б) тормышның фанилыгы, әҗәлнең рәхимсезлеге;
В) дөньяның матурлыгы;

14. Өмми Камал иҗатының төп үзенчәлеген атагыз.
А) төп тема-иҗтимагый гаделлек;
Ә) тулысыча суфичылык рухында;
Б) иҗат җимешләре гомумән сакланмаган;
В) сәяси лирика өстенлек итә;

15. Мөхәммәд Әминнең билгеле булган бердәнбер әсәрен атагыз.
А) “Гыйкаб” (“Үч”) шигыре;
Ә) “Нуры содур” поэмасы;
Б) “Бабахан дастаны”
В) әсәрләре бөтенләй саланмаган;

16. Мөхәммәд Әмин ханның кабередә кайсы әдип сакчы булып тора?
А) Мөхәммәдьяр;
Ә) Өмми Камал;
Б) Г.Тукай;
В) Утыз Имәни;

17. Түбәндәге әсәрләрнең кайсысы Мөхәммәдьяр тарафыннан язылмаган?
А) “Нуры содур” поэмасы;
Ә) “Төхфәи мәрдан” поэмасы;
Б) “Береккәннәр сыйфаты” поэмасы;
В) “Нәсыйхәт” шигыре;

18. “Нәсыйхәт” шигыренең төп мәгънәсе нәрсәдә?
А) кеше үзенең күңелен пакъ, нурлы тотарга тиеш;
Ә) мәхәббәт-иң күркәм хис;
Б) җәннәттән дә әһәмиятлерәк нәрсә юк;
В) суфиларның төп сыйфаты-фидәкарьлек;

19. Мөхәммәдьярның “Нуры содур” һәм “Төхфәи мәрдан” поэмаларын нәрсә берләштерми?
А) үзәкләрендә әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләр тора;
Ә) лиро-эпик жанрга карыйлар;
Б) тартмалы композициягә корылганнар;
В) бер үк елны язылганнар;

20. Мөхәммәдьяр идеаль хөкемдар дип кемне санаган?
А) Мөхәммәд Әминне;
Ә) Нәүширванны;

Б) Чынгызханны;

В) Атилланы;

21“Нуры содур” поэмасындагы “Хәммал хикаяте” нәрсә турында?

А) Йөк ташучының, актык акчасын җәлләмичә, авыр хәлдәге кешене коткарганны өчен бәхеткә ирешүе;

Ә) бүре белән куйның бер-берсеннән курыкмыйча бергә су эчүе;

Б) Нәүширван исемле патшаның үз иле белән бик гадел рәвештә идарә итүе;

В) ике сөешкән ярның, төрле бела-казаларны үтеп, бәхетле гаилә корулары;

22. Лирик каһарман-ул...

А) язучының үзе;

Ә) шагыйрь махсус рәвештә тудырган символ;

Б) хыял, әдәби чаралар ярдәмендә тудырылган образ, сүрәт;

В) киң таралган сүрәтләү чарасы;